| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ НОВОАЛИМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛЕМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
| 423762, село Новое Алимово, улица Г.Тукая, дом 55. | | 423762, Яңа Әлем авылы . Г.Тукай урамы, 55 йорт. |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**От 04.06.2021 г** **№ 10**

Яңа Әлем авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 37 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Конституция судының 2021 елның 19 апрелендәге 14-П номерлы карары, «Россия Федерациясе Граждан кодексының 209 статьясындагы 2 пунктының, Федераль законның 10 статьясындагы 7 өлешенең, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» конституциячелекне тикшерү турындагы эш буенча, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 22 абзацы, 16 статьясындагы 1 өлешенең 25 пункты һәм 45 статьясының 2 өлешенең 3 пункты нигезендә, гражданнар Г.С.Дадашов, И.Н.Касыймов һәм башкаларның шикаятьләренә бәйле рәвештә,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Яңа Әлем авыл җирлеге **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Яңа Әлем авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 31 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Төзекләндерү кагыйдәләренең 135,13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

135.13. «сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләрен, палаткалар, киосклар, лареклар, кече базарлар, павильоннар, җәйге кафелар, җитештерү объектларын, автомобильләр, көнкүреш техникасын, аяк киемен вак-төяк ремонтлау предприятиеләрен, шулай ук автостоянкаларны, кунакханәдән кала, торак бинага 10 метрдан да ким булмаган арага урнаштырырга кирәк»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында « Яңа Әлем авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Әлем авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе **Д.М.Әнвәрова**